## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Әтрәкле авыл җирлегенең Рус Мөшегесе торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

20 ноябрь 2025 № 14

2025 елның 20 мартында кабул ителгән № 33-ФЗ «Бердәм җәмгать хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Россия Федерациясе Федераль законының 45 нче һәм 69 нчы маддәләре, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы "Әтрәкле авыл җирлеге" Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Әтрәкле авыл җирлегенең Рус Мөшегесе торак пунктында халык җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Әтрәкле авыл җирлегенең Рус Мөшегесе торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Рус Мөшегесе торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (гравий сатып алу, ташу, салу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны Әтрәкле авыл җирлегенең мәгълүмат такталарында урнаштырырга, Минзәлә муниципаль районының http://menzelinsk/tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында гамәлдәге законнарга туры китереп бастыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Әтрәкле авыл җирлеге башлыгы А.М. Гыйльмуллин